РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление Карар

“15” июль 2019 ел. № 15

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 елдагы 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Расларга:

1.1. Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта);

1.2. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3. Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында (3 нче кушымта);

1.4. Документлар күчермәләренә һәм алардан өземтәләргә тугрылык таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта);

1.5. Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты: васыять таныклыгы яки ышанычнамә таныклыгы (5 нче кушымта);

1.6. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 кушымта);

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 25 июнендәге 10 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru) рәсми сайтында,

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе /А.И.Зиатдинов/